**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Югары Налим авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№ 162** **19.03.2020 ел**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 декабрендәге 157 номерлы "Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорына бюджеты турында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 декабрендәге 157 номерлы "Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорына бюджеты турында" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 1 пунктында:

а) 1 өлештә "5760,7" үзгәрешсез;

б) 2 өлештә "5760,7" санын "5975,3" санына алмаштырырга";

в) 3 өлештә "0" санын "214,6" санына алмаштырырга.

1.2. 1 нче кушымтаның 1 нче таблицасына "2020 елга Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары"н әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә һәм редакциядә бәян итәргә;

1.3. 2 нче кушымтаның 1 нче таблицасына "Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлегенең 2020 нчы елга фаразланган керем күләме" н әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә һәм редакциядә бәян итәргә;

1.4. 5 нче кушымтаның 1 нче таблицасына «2020 нчы елга Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә һәм редакциядә бәян итәргә;

1.5. 6 нче кушымтаның 1 нче таблицасына "2020 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре буенча Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлү"гә үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә редакциядә бәян итәргә;

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда бастырып чыгарырга, "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Югары Налим авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Н. Николаева**